ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унтугызынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе турында.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мактаулы Рәисен сайлау турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфаларын башкаруны йөкләү турында.
5. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
6. 2025 елда Татарстан Республикасы Конституция советы эшчәнлеге турында доклад.
7. «2025 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
8. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы.
9. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы.

10. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 165-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 166-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 163-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 83 һәм 98 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 164-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 65 һәм 66 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 1133108-8 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль милектәге җир кишәрлекләрен комплекслы үсеш территорияләре чикләренә кертү тәртибен төгәлләштерү турында).

15. «Бөртекле ашлык турында» Россия Федерациясе Законының $17^1$ һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1148367-8 номерлы федераль закон проекты турында (бөртекле ашлыкның һәм бөртекле ашлыкны эшкәртү юлы белән алынган продуктларның сыйфатын һәм иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметын киңәйтү өлешендә).

16. «Җирләрне һәм җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

17. «Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 1138192-8 номерлы федераль закон проекты турында (нотариаль гамәлләр башкарганда видеотеркәү чараларын куллану мәсьәләсе буенча).

18. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 47595-8 номерлы федераль закон проекты хакында (салым түләүче мөлкәтенә алдан вакытлыча чикләү чаралары кертү тәртибе турында).

19. Хөкүмәт сәгате: «Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында».

20. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 578-VII ДС